

Мордовия Республикасы Дәvләт Собраниесе республикада региональ һәм федераль максатчан программаларны тормышка ашыру буенча актив эш алып бара.
Анын ярдәме белән «Сәламәт киләчәк буын» дигән «Бердәм Россия» партия проекты кысаларында оештырылган «Су һәм саулык» Ботенроссия акциясе эш нәтижәләрен йомгаклап, тантаналары рәвештә проектта жингәннәрне котлау регионыбыз Госсобраниесе бинасында vтте. Тантананы Мордовия Дәvләт Собраниесе рәисе урынбасары Иван Михайлович Москаев алып барды.      2018 елнын январендә башланган Проект кысаларында шактый эш башкарылган. Иван Михайлович: «...Кечкенә Мордовия республикабыз бу проектны, олы Санкт-Петербург шәһәре, Татарстан, Ленинград, Пенза, Тvбән Янашәһәр олкәләре һәм башка зур регионнар тосле лаеклы vткәрде, - ди чыгышында. - Мордовиядә «Су һәм саулык» Ботенроссия акциясендә барлыгы 53 642 кеше катнашты. 387 гомуми белем бирv мәктәбенен 2339 укучысы белән 1236 отчет әзерләнде һәм 2628 ачык дәресләре vткәрделәр, дип сойләде трибунадан Иван Маскаев. - Укучылар, житәкчеләре ярдәме белән, зур эш башкардылар: сунын кыйммәте турында сойләшvләр, су сыйфатын ойрәнv буенча тәжрибәләр (тиешерv нәтижәсендә краннан аккан суыбыз, чишмәләгә караганда, чистарак һәм куллану очен куркынычсызрак икән), эпидемиология һәм гигиена Үзәгендә 300 якын эко-дәресләр, чишмәләр һәм су буйларын чистарту буенча эко-десантлар, презентация белән партфолио-лар, мастер-класслар, сыйныфтан тыш һәм башка чаралар vткәрделәр. Кайбер катнашучылар 200 экология темасын ачыклаган яналык



социаль челтәрләрдә бастырганнар. Эшләргә нәтижә иттереп акциянен федераль штабы укучыларнын тырыш хезмәтен «Артек» халыкара балалар ял лагерынын экологик унынчы сменасына 15  һәм Мордовиянен активлыгын тагын  5 юллама-путевкалар белән бvләкләде. Шулай итеп, 20 жинvче киләсе атнада ук ял йортына юлланырлар».

Алар арасында федераль дәрәжәдә жинеп чыккан Саранск шәһәре 24нче мәктәбе укучысы Арюков Марат һәм региональ кvләмдә жинvче Рузаевка шәһәре 7 номерлы мәктәбе укучысы Рахмукова Карина иде. Марат аралашканда: «Су – яшәv чыганагы: кеше очен дә, vсемлек, хайваннар, кош-кортлар очен дә, гомумән, ботен тереклек очен. Гасырлар буенча ничәмә-ничә буын кешеләргә яшәр очен су коч һәм сихәт биреп тора. Шуны саклый белергә тиешбез. Шул һәм башка темаларны ачыклап 5-11 сыйныф укучыларына эко-дәресләр vткәрдем, презентация ясадым, эко-десантта катнаштым», - ди.
Мордовия  Дәvләт Собранисе бинасында «Сәла-мәт киләчәк буын» дигән  «Бердәм Россия» партия проекты кысаларында оештырылган «Су һәм саулык» Ботенроссия акциясе кураторларын, жинvчеләрнен житәкчеләрен дә тантаналы рәвештә бvләкләделәр. «Бердәм Россия» партия региональ бvлеге сәркәтибе, Мордовия Дәvләт Собраниесе рәисе Владимир Васильевич Чибиркин исеменнән «Бергә vткәрәбез!» Ботенроссия экология акциясен унышлы vткәрергә ярдәмнәре очен Рәхмәтен (Благодарность) региональ штаб сәркәтибе, социаль сәясәт эшләре буенча Саранск департаменты директоры урынбасары Ольга Ручинага, региональ штаб әгъзасы, Госдума депутаты Василий Пискаревнын ярдәмчесе Ольга Суродеевага, министрлыклар һәм ведомстволар, мәктәп директорларына, укытучыларга, волонтерларга тапшырдылар.
Әйтеп китәргә кирәк, Дәvләт Собраниесе депутатлары бу эштә актив булдылар. Торле сайтларда аларнын эше чагылды. Шулай, Дубенка районы мәктәбендә «Табигатьтә һәм кеше тормышында сунын роле» темасына багышланган эко-дәрестә Дәvләт Собраниесе депутаты Ринат Рафик улы Раимов катнашты. Ул укучыларга сунын кыйммәте турында сойләде. Ринат Рафик улы, «Мордовиянен чишмә суы» компаниясе житәкчесе буларак, коннән-кон чиста су табу проблемага әйләнеп килә, ди.  Шуна чишмәләрне, су чыганакларын һәрвакыт чисталыкта тотарга, табигатьне сакларга чакырды.

**Наилә Насырова**